ГЛАВА САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2019 с. Сарманово № 227

Сарман муниципаль районының гражданнар оборонасы һәм гадәттәнтыш хәлләрдән яклау буенча укыту-консультация пунктлары төзү турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 декабрендәге 28 -ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны укытуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау турында» 2000 елның 02 ноябрендәге 841 номерлы карарын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 21 маендагы 1126-р номерлы боерыгын үтәү йөзеннән

КАРАР БИРӘМ:

1. Граждан оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдән саклау буенча укыту-консультация пунктларын (алга таба - ГОЧС буенча УКП) түбәндәге базада төзергә:

- «Үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет учреждениесенең район мәдәният йорты,аңа Сарман авылы, Яңа Әхмәт авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- «Җәлил мәдәният сарае» муниципаль бюджет учреждениесе (Җәлил б.), аңа Җәлил бистәсе, Абдрахман авылы, Яңа Минзәләбаш авылы, Кызыл Бакча авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Саклаубаш авылы мәдәният йорты (Саклаубаш авылы), аңа Саклаубаш авылы, Алга авылы, Сулы Саклау авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Зур Нөркәй авыл мәдәният йорты (Зур Нөркәй авылы),аңа Зур Нөркәй авылы, Кече Нөркәй авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Янурыс авылы мәдәният йорты (Янурыс авылы), аңа Янурыс авылы, Каташ-Каран авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Петровский-Завод авыл мәдәният йорты (Петровский Завод ав.), аңа Петровский-Завод авылы, Пробуждение авылы, Кук-Тау авылы, Дими-Тарлау авылы, Мостафино авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Рангазар авылы мәдәният йорты (Рангазар авылы), аңа Рангазар авылы, Рантамак авылы, Бал-Тамак авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Александровка авылы мәдәният йорты (Александровка авылы), аңа Александровка авылы, Татар Карамалы авылы, Яхша Каран авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Күтәмәле авылы мәдәният йорты (Күтәмәле авылы), аңа Күтәмәле авылы, Яңа Имән авылы, Таза Чишмә авылы, Буралы Чишмә авылы, Ивановка авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Ләке авыл мәдәният йорты (Ләке авылы),аңа Ләке авылы, Дружба авылы, Язык авылы, Ферма Савекле авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

- Карашай-Саклау авыл мәдәният йорты (Карашай-Саклау авылы),аңа Карашай-Саклау авылы,Чураш авылы составындагы хезмәт күрсәтү зоналарын беркетеп;

2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

- ГОЧС буенча УКП эшчәнлеген оештыру һәм оештыру мәсьәләләре буенча кирәкле норматив документлар чыгарырга;

- мәдәният йортлары (авыл клублары) җитәкчеләренә ГОЧС буенча төзелә торган УКП укыту-матди база белән тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә.

3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән авыл җирлекләре башлыкларына - ГОЧС буенча УКП составын укыту-консультация пункты башлыгы һәм 1-2 инструктор составында штаттан тыш нигездә формалаштырырга тәкъдим итәргә.

4. «Сарман муниципаль районы УГЗ» МКУ башлыгына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән авыл җирлекләре башлыкларына ГОЧС буенча УКП төзүдә һәм эшчәнлеген оештыруда методик һәм гамәли ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. ГОЧС буенча УКП төзү гамәлләрен финанслау Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчалары исәбеннән гамәлгә ашырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Сарман муниципаль
районы Башлыгы

Ф.М. Хөснуллин